МИНИСТЕРСТВО
ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
УРМАН ХУҖАЛЫГЫ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.06.2024 № 222-осн

Казан ш.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында» 2023 елның 19 сентябрендәге 422-осн номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актны Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссияләре турында» 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы Указына туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында» 2023 елның 19 сентябрендәге 422-осн номерлы боерыгына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Юридик бүлек җитәкчесенә (Т.А. Барсукова) боерык имзаланган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек чорда аны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр Р.Ә. Кузюров

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2024 елның ____________ №_____ боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында» 2023 елның 19 сентябрендәге 422-осн номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

1. Әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлегендә:

1.3 пунктның икенче кызыл юлын түбәндәгечә үзгәртеп бирергә:

«Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре, Министрлык) мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмый калу яисә җайга салу турында чикләмәләрне һәм тыюларны, таләпләрне үтәвен тәэмин итүдә, шулай ук коррупциягә каршы тору максатларында алар тарафыннан «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законда, башка федераль законнарда билгеләнгән бурычлар үтәлешен (алга таба – хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу) тәэмин итүдә;»;

III бүлектә:

3.1 пунктны түбәндәге эчтәлектәге «е» пунктчасы белән тулыландырырга:

«е) дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәүгә һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга комачаулаучы, аңа бәйле булмаган шартлар барлыкка килүе турында хәбәр итүе.»;

3.4.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктчасындагы бишенче абзацта һәм «е» пунктчасында күрсәтелгән белдерүләр коррупциячел һәм башка төр хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы булган вазыйфаи зат тарафыннан карала, ул белдерүләрне карау нәтиҗәләре буенча нигезләнгән бәяләмә әзерли.»;

3.4.2 пунктында «3.1 пунктының «д» пунктчасында» сүзләрен «3.1 пунктның «д» һәм «е» пунктчаларында» сүзләре белән алмаштырырга;

3.4.3 пунктта:

«а» пунктчасында 3.1 пунктының «д» пунктчасында» сүзләрен 3.1 пунктның «д» һәм «е» пунктчаларында» сүзләре белән алмаштырырга;

«в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында, «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән

мөрәҗәгатьләрне яисә белдерүләрне беренчел карау нәтиҗәләре буенча нигезләнгән нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.13, 3.15.1, 3.18, 3.18.1 пунктлары нигезендә карарларның берсен яисә башка төрле карарны кабул итү өчен киңәшләр.»;

3.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән белдерүләр, кагыйдә буларак, Комиссиянең чираттагы (планга кертелгән) утырышында карала.»;

3.8 пунктта «3.1 пунктның «б» пунктчасы белән» сүзләрен «3.1 пунктның «б» һәм «е» пунктчалары белән» сүзләренә алмаштырырга;

3.8.1 пунктның «а» пунктчасында «3.1 пунктның «б» пунктчасы белән» сүзләрен «3.1 пунктның «б» һәм «е» пунктчалары белән» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлектәге 3.18.1 пункт белән тулыландырырга:

«3.18.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «е» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган шартларның барлыкка килүе һәм аларның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәүгә һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга мөмкинлек бирмәве арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булуын танырга;

б) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган шартларның барлыкка килүе һәм аларның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәүгә һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга мөмкинлек бирмәве арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булмавын танырга.»;

3.19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.19. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктының «а», «б», «г», «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау йомгаклары буенча һәм, моңа нигезләр булган очракта, Комиссия әлеге Нигезләмәнең 3.11-3.15.1, 3.17-3.18.1 пунктларында каралганнан башкачарак карар кабул итә ала. Мондый карар кабул итүнең нигезләре һәм мотивлары Комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.».

2. Әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе составын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясенең составы

| | |
|---|---|
| Зарипов Илгизәр Наил улы | Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министрының беренче урынбасары (Комиссия рәисе) |
| Гомәров Рәис Кәлимулла улы | министр урынбасары (Комиссия рәисе урынбасары) |
| Комиссия секретаре: | |
| Зыятдинова Эльвира Вәккас кызы | дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре |

| | |
|---|---|
| | секторы мөдире |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Әхмәдуллин Фәнил Фәиз улы | аренда мөнәсәбәтләре бүлеге җитәкчесе |
| Әхмәров Айрат Фәргат улы | дәүләт контроле һәм күзәтчелек бүлеге җитәкчесе |
| Барсукова Татьяна Анатольевна | юридик бүлек башлыгы |
| Булатова Чулпан Гарәфетдин кызы | финанс, бухгалтерлык исәбе һәм контроль бүлеге җитәкчесе – баш хисапчы |
| Жирнова Галина Ивановна (килешү буенча) | «Казан (Идел буе) федераль университеты» ЮБ ФДАМУ Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе директоры киңәшчесе |
| Зарипов Илгиз Нәҗип улы (килешү буенча) | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет вәкиле |
| Имамиев Нияз Илдус улы | мөлкәт белән идарә итү, техник үсеш һәм хезмәт сагы бүлеге җитәкчесе |
| Калашникова Ольга Анатольевна (килешү буенча) | Россия Федерациясе дәүләт учреждениеләре һәм иҗтимагый хезмәт күрсәтү хезмәткәрләре профсоюзының Татарстан республика оешмасы рәисе |
| Шагаева Эльмира Минталиб кызы | эшләр идарәчесе |
| Шрша Равия Бәдертдин кызы (килешү буенча) | Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенең коррупциягә каршы тикшерүләр бүлеге мөдире |

».